**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**29 октябрь, 2018 ел** **№ 256**

**Биектау муниципаль районы авыл җирлекләренә себер түләмәле калдыкларны күмү урыннарын һәм үләт базларын (биотермик чокырларны) карап тотуга һәм төзекләндерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүне оештыру вәкаләтләрен тапшыру турында**

РФ Бюджет кодексының 142.4 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә, 63 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, күзәтүчесез хайваннарны тоту һәм карап тоту, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән саклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юк итү буенча ветеринария-санитария кагыйдәләре»нә (РФ Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы 04.12.1995 N 13-7-2/469 раслаган) (16.08.2007 редакциясендә), Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. Биектау муниципаль районының кушымтада күрсәтелгән авыл җирлекләренә себер түләмәле калдыкларны күмү урыннарын һәм үләт базларын (биотермик чокырларны) карап тотуга һәм төзекләндерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүне оештыру вәкаләтләрен түбәндәге өлешләрдә тапшырырга:

- себер түләмәле калдыкларны күмү урыннарын һәм үләт базларын (биотермик чокырларны) (алга таба шулай ук - объектлар) карап тоту, шул исәптән аларны төзекләндерү. Себер түләмәле калдыкларны күмү урыннарын һәм үләт базларын (биотермик чокырларны) төзекләндерү дигәндә, себер түләмәле калдыкларны күмү урыннарын һәм үләт базларын (биотермик чокырларны) ветеринария-санитария

кагыйдәләре нигезендә агымдагы карап тоту, эксплуатацияләү һәм капиталь ремонтлау чаралары комплексы аңлашыла;

- ветеринария-санитария кагыйдәләре нигезендә объектларны карап тоту һәм эксплуатацияләү чараларын күрү;

- себер түләмәле калдыкларны күмү урыннарын һәм үләт базларын (биотермик чокырларны) консервацияләү. Себер түләмәле калдыкларны күмү урыннарын һәм үләт базларын (биотермик чокырларны) консервацияләү дигәндә, ветеринария-санитария кагыйдәләре нигезендә себер түләмәле калдыкларны күмү урыннарын һәм үләт базларын (биотермик чокырларны) траншеялар белән канаулау һәм бетонлау чаралары комплексы аңлашыла;

- объектларның техник планнарын һәм (яисә) кадастр паспортларын рәсмиләштерү.

2. Биектау муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне башкаруга авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү вәкаләтләрен бирергә.

3. Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлегенең Вәкаләтләрне үтәүгә финанс чаралары Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетыннан авыл җирлекләре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә төзелгән Килешүләр нигезендә бирелә.

4. Биектау муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллинга йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин

Биектау муниципаль районы
Советының 2018 елның
29 октябрендәге 256 номерлы
карарына кушымта

| N т/б | Урынны тасвирлау | Авыл җирлеге |
|---|---|---|
| 1. | 1) Айбаш ав. 1,5 км төньяк-көнбатышка (2данә) | Айбаш |
| 2. | 1) Каенлы ав. 900м көньяктарак<br>2) Шуман 1,2 км төньяк-көнчыгыштарак<br>3) Чыршы ав. 800м көнчыгыштарак<br>4) Соловцово ав. 50м көньяктарак | Каенлык |
| 3. | 1) Сосновка ав.1,5 км көньяк-көнчыгышка | Бөреле |
| 4. | 1) Битаман ав. 1 км төньяк-көнбатышка<br>2) Ювас ав.1,5 км төньяк-көнбатышка<br>3) Олы Битаман ав. 400 м көнчыгышка | Олы Битаман |
| 5. | 1) Чуаш Иле ав. 2 км көнбатышка | Олы Кавал |
| 6. | 1) Торнаяз ав. 300 м төньяк-көнбатыштарак | Дөбъяз |
| 7. | 1) Коркачык ав.500 м көнбатыштарак<br>2) Югары Ия ав. 3 км төньякка<br>3) Татар Урматы ав. 500 м төньяк-көнбатышка (2 данә) | Иске Казан |
| 8. | Өллә ав.1 км төньяк-көнбатышка | Казаклар |
| 9. | 1) Мәмдәл ав. 1,2 км көнчыгышка<br>2) Юртыш ав. 3 км көнчыгышка | Мәмдәл |
| 10. | 1) Мүлмә ав. 1 км көньяк-көнчыгышка<br>2) Мүлмә ав. 1,5 км көнбатыштарак<br>3) Сасмак ав. 1 км көньякка<br>4) Болгар ав. 800 м көньякка<br>5) Тимерче ав.1,5 км төньяк-көнбатышка | Мүлмә |
| 11. | Күлле пос.1 км төньяк-көнчыгышка | Семиозерка |
| 12. | Суыксу ав.1 км төньяк-көнбатышка | Суыксу |
| 13. | Ташлы Кавал ав. 500 м төньяк-көнчыгышка | Ташлы Кавал |
| 14. | Кече Бөреле ав. 800 м төньяк-көнчыгышка | Чыпчык |
| 15. | 1) Кызыл Шәрык ав. 1 км көнчыгышка<br>2) Тимошкино ав. 1 км көнчыгышка<br>3) Шәпше ав. 700 м төньяк-көнбатышка | Шәпше |
| 16. | Ямаширмә ав. 1 км төньякка<br>2) Ямаширмә ав. 850 м төньякка | Ямаширмә |